ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә
кабул ителде

## 1 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 пунктчасында «республика максатчан программаларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

2) 9 статьяның 3 пунктында «мелиоратив ышыклагыч урман утыртмалары» сүзләрен «агроурманмелиоратив утыртмалар, агрофитомелиоратив утыртмалар» сүзләренә алмаштырырга;

3) 12 статьяның 6 пунктында «табигый комплексларына» сүзләрен «табигый экологик системаларына, табигать комплексларына һәм үсемлекләр, хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеге булган объектларына» сүзләренә алмаштырырга;

4) 25 статьяда:

а) 1 пунктта «авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә туфракның уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшырту» сүзләрен «җирләрнең үзенчәлекләрен яхшырту, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктның 3 пунктчасында «мелиоратив ышыклагыч урман утыртмаларын» сүзләрен «агроурманмелиоратив утыртмаларны» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда аларның үз көченә керүенең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пункты 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 70-ТРЗ